РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.01.2020 Олы Кайбыч ав. № 2

Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, 2020 елга су объектларында янгын куркынычсызлыгын һәм кешеләрнең куркыныч-сызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Кайбыч муниципаль районының төп чаралары планын һәм 2020 елга Кайбыч муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча идарә органнарын, гражданнар оборонасы көчләрен һәм территориаль өстәмә системаны әзерләү буенча оештыру-методик күрсәтмәләрне раслау турында

Киләчәктә Кайбыч муниципаль районының идарә органнары, гражданнар оборонасы көчләре һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль подсистемасын әзерләү дәрәҗәсен арттыру максатларында КАРАР ИТӘМ:

1. Кушымта итеп бирелә торганнарны расларга:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, 2020 елга су объектларында янгын куркынычсызлыгын һәм кешеләрнең куркынычсызлы-гын тәэмин итү буенча төп чаралар планын;

2020 елга Кайбыч муниципаль районының идарә органнарын, гражданнар оборонасы көчләрен һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системаларын әзерләү буенча оештыру-методик күрсәтмәләрне.

2. Кайбыч муниципаль районы предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләренә Кайбыч муниципаль районының гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, 2020 елга су объектларында янгын куркынычсызлыгын һәм кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча төп чаралар планы үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына, район предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә билгеләнгән тәртиптә тиешле планнар эшләргә һәм гамәлгә кертергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А.Н. Макаровка йөкләргә.

А.И.Рәхмәтуллин